РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«25» октябрь 2022 ел г. Альметьевск № 2451

**Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 08 февралендәге 212 номерлы карарына үзгәреш кертү турында**

«Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалашканда исәпкә алына торган гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган Граждан оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә, Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр барлыкка килгәндә исәпкә алына торган су объектларында янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең иминлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнар күләмен билгеләү методикасына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 15 сентябрендәге 1007 номерлы карары нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы

Зак. № 305-2000

гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 08 февралендәге 212 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 11 июлендәге 962 номерлы, 2020 елның 14 декабрендәге 1838 номерлы, 2021 елның 02 мартындагы 281 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Карарга 1 нче кушымтада:

2 бүлекнең 1 пунктындагы 1 нче таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Табл.№ 1

| № п/п | Хезмәткәрләр вазыйфалары | Вазыйфаи оклад күләме, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Идарә башлыгы | 19 862,0 |
| 2 | Оператив дежурный | 15 279,0 |

3 бүлекнең 1 пунктындагы өченче абзацын төшереп калдырырга.;

3 бүлекнең 2 пунктын төшереп калдырырга;

3 бүлекнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Даими нигездә дәүләт серенә кертелгән хезмәткәрләргә дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләр белән эшләгән өчен елына 0,3 вазыйфаи оклад күләмендә айлык өстәмә түләү түләнә.

Дәүләт серен төзи торган белешмәләр белән эшләгән өчен күрсәтелгән айлык өстәмә дәүләт серенә даими нигездә кертелгән хезмәткәрләргә, рөхсәт законда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән очракта, түләнә.».

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

- Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 11 июлендәге 962 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 8 июлендәге 962 номерлы карары;

- Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 8 февралендәге 212 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Әлмәт муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 14 декабрендәге 1838 номерлы карары;

- Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 8 февралендәге 212 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 2 мартындагы 281 номерлы карарының 1 пунктындагы 6,7 абзацы.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов